# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
# ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

## КАРАР

«31» 10 2024 ел Яр Чаллы №4890

Балаларны йөртү өчен махсус билгеләнгән автобусларда Тукай муниципаль районы гомуми белем бирү оешмалары укучыларын йөртүне оештыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең 2025 елга бәя нормативларын раслау турында

«Балаларны йөртү өчен махсус билгеләнгән автобусларда гомуми белем бирү оешмалары укучыларын йөртүне финанслау нормативларын исәпләү буенча методик киңәшләрне раслау турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 5 июлендәге 545 номерлы карарының 3 пунктын үтәү йөзеннән, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы «Татарстан Республикасының икътисадый һәм социаль тикшеренүләр үзәге» дәүләт бюджет учреждениесенең 2024 елның 4 сентябрендәге 01/1451 номерлы хаты нигезендә Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Раслрга:

1.1. Балаларны йөртү өчен махсус билгеләнгән автобусларда гомуми белем бирү оешмалары укучыларын йөртүне оештыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең 2025 елга бәя нормативларын.

1.2. Балаларны йөртү өчен махсус билгеләнгән автобусларда гомуми белем бирү оешмалары укучыларын йөртүне оештыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтү бәясен исәпләү тәртибе турында нигезләмәне.

2. «Тукай муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең финанс-бюджет палатасына балаларны йөртү өчен махсус билгеләнгән автобусларда гомуми белем бирү оешмалары укучыларын йөртүне оештыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең әлеге карарның 1 пуктында расланган бәя нормативлары нигезендә финанслауны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарны районның рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында урнаштырырга.

4. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Башкарма комитет Җитәкчесе А.Р. Хәбибуллин

Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесенең 2024 елның 31 10 4890 номерлы карары белән расланган

Балаларны йөртү өчен махсус билгеләнгән автобусларда гомуми белем бирү оешмалары укучыларын йөртүне оештыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең 2025 елга бәя нормативлары

| Автотранспорт чарасы моделе исеме | Ике ставкалы норматив күләме | |
|---|---|---|
| | бер автотранспорт чарасына ставка, бер елга сумнарда | автотранспорт чарасы узган бер километрга ставка, бер елга сумнарда |
| КАВЗ | 1 128 838,81 | 24,40 |
| ПАЗ | 1 129 096,31 | 24,56 |
| ГАЗ «Газель» | 1 107 926,16 | 15,73 |
| УАЗ | 1 107 472,96 | 14,08 |
| FIAT | 1 110 820,46 | 11,88 |
| Peugeot Boxer | 1 115 970,46 | 11,47 |
| Ford Transit | 1 116 227,96 | 16,08 |
| Камаз Марко-Поло 3297 | 1 131 053,31 | 21,60 |

Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесенең 2024 елның 31 10 4890 номерлы карары белән расланган

# Гомуми белем бирү оешмалары укучыларын балаларны йөртү өчен махсус билгеләнгән автобусларда йөртүне оештыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтү бәясен исәпләү тәртибе турында нигезләмә

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге нигезләмә гомуми белем бирү оешмалары укучыларын балаларны йөртү өчен махсус билгеләнгән автобуслар белән йөртүне оештыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтү (алга таба – муниципаль хезмәт) бәясен исәпләү механизмын билгели.

1.2. Муниципаль хезмәт күрсәтү бәясе муниципаль хезмәт күрсәтү бәясе нормативы, автотранспорт чаралары саны һәм хисап чорында автотранспорт чараларының факттагы йөреше нигезендә исәпләнә.

1.3. Муниципаль хезмәт күрсәтү бәясе нормативлары ел саен «Тукай муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты тарафыннан раслана.

1.4. Муниципаль хезмәт күрсәтү бәясен формалаштырганда автотранспорт чараларының фактик йөреше турында мәгълүмат, автотранспорт чарасының расланган маршруты паспорты кысаларында автотранспорт чарасының хисап елында факттагы йөреше буларак, Татарстан Республикасында автотранспорт чараларының аерым төрләрен мониторинглауның бердәм системасы белешмәләре буенча кабул ителә.

## 2. Муниципаль хезмәт күрсәтү бәясен исәпләү

2.1. Муниципаль берәмлекнең муниципаль хезмәт күрсәтү бәясе түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$S_i = \sum_{m=1}^{k} (n_{f\,m} \times NF_{km_m} + NF_{as\,m} \times M_m),$$

биредә:

$S_i$ – муниципаль хезмәт күрсәтү бәясе;

$n_{f\,m}$ - $m$ моделендәге автотранспорт чараларының фактик йөреше, километрларда;

$NF_{km_m}$ - гомуми белем бирү оешмалары укучыларын балаларны йөртү өчен махсус билгеләнгән автобусларда йөртүне оештыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтү бәясе нормативы ставкасы, бер километрга, сумнарда;

$NF_{as\,m}$ - гомуми белем бирү оешмалары укучыларын балаларны йөртү өчен махсус билгеләнгән автобусларда йөртүне оештыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтү бәясе нормативы ставкасы, бер автотранспорт чарасына, сумнарда;

$M_m$ - $m$ моделендәге автотранспорт чаралары саны, берәмлекләрдә;

$m$ - муниципаль берәмлектә файдаланыла торган автобус моделенең номеры;

$k$ - муниципаль берәмлектә файдаланыла торган автобус модельләренең саны.